# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИБӘХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**бишенче чакырылыш дүртенче утырыш**

Keче Кибәхуҗа ав. **№ 18** 16 декабрь 2025 ел

**Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 18 май 2023 ел 76 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 18 май 2023 ел 76 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1) физик затның Россия Федерациясе Граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булуы яисә вафат булуы турында игълан ителүе (мондый физик затка карата банкротлык турында эш кузгатылган очрактан тыш):

-РФ Салым кодексының 15 статьясының 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелмәгән салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча бурычлар өлешендә;

-РФ Салым кодексының 15 статьясының 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артыграк күләмдә бурыч өлешендә, шул исәптән мирас Россия Федерациясе милкенә күчкән очракта да;

-РФ Салым кодексының 15 статьясының 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артмаган күләмдәге бурыч өлешендә мондый физик зат вафат булганнан соң өч ел узгач һәм салым органында мондый мөлкәтне мирас итеп алу факты турында мәгълүмат булмаганда;".

2. Әлеге карарның 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керүен билгеләргә.

3. Әлеге карарны " Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Теләче муниципаль районының Кече Кибәхуҗа авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башлыгы: И.Г. Заһидуллин